**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**19 сентябрь, 2022 ел** **№ 206**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Территорияне тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу, « Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә нәтиҗәле һәм тәртипкә салынган җирдән файдалануны һәм төзелешне тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы, Биектау муниципаль районының 2022 елның 09 сентябрендә узган гавами тыңлаулары нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Кушымтада бирелгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен расларга.
2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дачный авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»24.06.2022 ел, № 177 Биектау муниципаль районы Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча, һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4 Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамөтдинов

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дачный авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 19.09.2022 ел, № 206 карарына материаллары белән с https://fgis-tp.ru. сайттында танышырга мөмкин.